**СОВЕТ МАКАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422602 с. Ташкирмень,
ул. Мира, д.40
тел: 4-85-25

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАКАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422602 Ташкирмән авылы,
Тынычлык урамы, 40 нчы йорт,
тел: 4-85-25

**110номерлы** **2019 елның 7 декабрендәге**

**карар**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге составына керүче Ташкирмән торак пунктындагы гражданнар җыены карары**.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Макаровка авыл җирлеге составына керүче Ташкирмән торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. . Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлеге Ташкирмән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2020 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертергә.

2. . Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча урындагы мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- Ташкирмән торак пунктында урам-юл челтәрен төзү, ремонтлау һәм карап тоту.

3. Әлеге карарны Макаровка авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында игълан итәргә: һәм http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Макаровка авыл җирлегенең әлеге карарын Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: _______________В.В.Кормачев
Башлык - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы-
Макаровка авыл җирлеге Советы рәисе _________________ В.В.Кормачев